СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

04.04.2023 Баулы шәһәре № 168

2023 елда Баулы муниципаль районы муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазифаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Баулы муниципаль районының муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров